ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ
III чакырылыш
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
III созыва
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

от 16.12.2019г №43-08

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле төрләренең һәм җирле үзидарә органнарының исемлеге турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, 2008 елның 26 декабрендә «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең мәгълүмати ачыклыгын тәэмин итү максатларында, Актаныш муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм муниципаль контроль төрләре исемлеген расларга (1 нче кушымта).

2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына Актаныш муниципаль районы территориясендә аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле муниципаль контроль төрләре һәм башкарма комитет органнары исемлеген алып баруны йөкләргә.

3. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле төрләренең һәм җирле үзидарә органнарының исемлеге турында» 2019 елның 9 ноябрендәге 41-12 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында веб-адрес буенча http://aktanysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмати порталында веб-адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә игълан итәргә.

Актаныш муниципаль районы Советы Рәисе Э.Н. Фаттахов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ ОГРН 1051667009734 ИНН 1604006751

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль район Советы карарына
16.12.2019 ел, №43-08
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле төрләре һәм җирле үзидарә органнары исемлеге

| т/б | Муниципаль контроль төре | Муниципаль контроль төрен гамәлгә ашыруны регламентлый торган норматив хокукый актлар (конкрет нигезләмә, статья, пункт, абзацларны күрсәтеп, реквизитларны да кертеп) | Муниципаль контроль төрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар (структур бүлекчәләр) |
|---|---|---|---|
| 1. | Муниципаль торак контроле | Россия Федерациясе Торак кодексы 20 ст.<br><br>2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары” 15 ст. | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге |
| 2. | Муниципаль җир контроле | Россия Федерациясе Җир кодексының 72 ст., "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 ст. 1 ө. 26 п.” | Актаныш муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы |
| 3. | Төзекләндерү өлкәсендәге муниципаль норматив хокукый актларның үтәлешенә муниципаль контроль | Татарстан Республикасы Экология кодексы;<br>Татарстан Республикасы Законы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 ел, 28 июль, 45-ТРЗ номерлы карары | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4. | Тышкы реклама һәм мәгълүмат тарату өлкәсендә норматив хокукый актларның үтәлешенә муниципаль контроль | Татарстан Республикасы Законы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 ел, 28 июль, 45-ТРЗ номерлы карары | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге |
| 5. | Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына муниципаль контроль | "Автомобиль юллары турында "2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 13 ст. 1 ө. | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге |
| 6. | Алкогольле продукцияне ваклап сату өлкәсендә законнарның үтәлешен контрольдә тоту | "Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләти җайга салу турында" 22 ноябрь, 1995 ел, № 171-ФЗ Федераль законның 7 статьясы | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге |